Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

**«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең 2019 елның 22 апрелендәге 2 номерлы "Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында"**

№ 1 “17” май 2021 ел.

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең 2019 елның 22 апрелендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында" гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 34 бүлегендәге 4 пунктта "(булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен" сүзләрен өстәргә.

1.2 19 Бүлегендәге 3 пунктның 4 пунктчасында "хезмәт кенәгәсе" сүзләреннән соң "һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр" сүзләрен өстәргә";

1.3 19 бүлегендәге 3 пунктның 6 пунктчасы "мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы" сүзләрен "индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ" сүзләренә алмаштырырга.

1.4 16 бүлегендәге 1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) түбәндәге очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләргә:

а) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына яки Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасына сайлану яисә билгеләү, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләнгән очракта;

б) муниципаль вазыйфага сайлау яисә билгеләү;

в) һөнәр берлеге органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органында, һөнәр берлеге органында, түләүле сайлау вазыйфасына сайлау;

1.5 32 бүлегендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә";

1.6 18 статьяның 13 пунктыннан соң "җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты" сүзләреннән соң "күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану турында" сүзләрен өстәргә;

1.7 28 бүлегендәге 6 пунктта "ә стаж дәвамлылыгы һәм айлык түләүләр әлеге кодекс нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук мәгънәдә исәпкә алына" сүзләрен "ә сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгеләүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив хокукый актында билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына".

1.8 4 Кушымтаның 19 бүлеге 3 статьясының 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ формасында";

1.9 статьясына 15 өлешнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4.Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»

2.Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Башлык И. З. Камалов